ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» февраль 2019 ел № 41

**Гражданнарны «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләү турындагы материалларны карау комиссиясе хакында**

Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 26 июлендәге 141 номерлы «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале турында карарын үтәү һәм бүләкләү эшләрен алдан карап тикшерү, «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләү турында бәяләмә чыгару максатларыннан, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. Гражданнарны «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләү турындагы материалларны карау комиссиясен 1 нче кушымта нигезендә төзергә.
2. Гражданнарны «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләү турындагы материалларны карау комиссиясе хакында Нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район Советы аппараты җитәкчесе И.С.Сабировка йөкләргә.

Балтач муниципаль
район башлыгы Р.Р.Нотфуллин

20.02.2019 №41
Балтач муниципаль районы
башлыгы карарына
1 нче кушымта

**Гражданнарны «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләү турындагы материалларны карау комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Сабиров И.С. | - Балтач район Советы аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Галимуллин И.С. | - Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Мөхәммәтҗанова Р. Х. | - Балтач район Советының оештыру бүлеге башлыгы, комиссия секретаре. |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Абдуллин Р.Г. | - Балтач районы ветераннар Советы рәисе (килешү буенча); |
| Гыйләҗева Г.Ф. | - Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Балтач муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе, Балтач урта мәктәбе директоры (килешү буенча); |
| Зәкиев В.М. | - Балтач муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе, «Татмедиа» ААҖ филиалы «Хезмәт» редакциясе баш мөхәррире (килешү буенча); |
| Низамиев Ш.В. | - Карадуган авыл җирлеге башлыгы, Карадуган авыл җирлеге депутаты (килешү буенча); |
| Нургалиев Р.К. | - Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы профсоюз оешмаларының Координацияләү советы рәисе (килешү буенча). |

20.02.2019 №41
Балтач муниципаль районы
башлыгы карарына
2 нче кушымта

**«Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләү турындагы материалларны карау комиссиясе хакында Нигезләмә**

Гражданнарны «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләү турындагы материалларны карау комиссиясе (алга таба - комиссия) бүләкләү эшләрен алдан карау, «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләү турындагы бәяләмәләрне чыгару максатларында төзелә, иҗтимагый башлангычларда үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы коллегиаль орган булып тора.

Комиссия эшчәнлегенең хокукый нигезен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, башка норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 26 июлендәге 141 номерлы карары белән расланган «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале турында Нигезләмә тәшкил итә.

Комиссия «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләү документларын 14 көннән дә соңга калмыйча карап тикшерә һәм комиссия утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә рәсмиләштерелгән бәяләмә рәвешендә Балтач муниципаль район башлыгына тәкъдим итә.

Комиссия үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен хокуклы:

- гражданнарны билгеләнгән тәртиптә бүләкләүгә тәкъдим ителә торган кирәкле материалларны һәм белешмәләрне милек формасына һәм нинди ведомствога ия булуга карамастан, предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләреннән, җирлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, Балтач муниципаль районының иҗтимагый оешмалары яисә башка вазыйфаи затлардан соратып алырга;
- билгеләнгән таләпләргә туры килми торган документларны карауга кабул итмәскә.

Гражданнарны «Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләү турындагы материалларны карау комиссия утырышларында башкарыла. Комиссия утырышын комиссия рәисе, ә аның юклыгында комиссия рәисе урынбасары җитәкли. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, комиссия утырышы хокуклы санала.

Карар комиссия әгъзалары саныннан ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез бүленгән очракта ахыргы карарны комиссия рәисе кабул итә, ә ул булмаганда - комиссия рәисе урынбасары.

Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм утырышта рәислек итүче комиссия рәисе яисә аның урынбасары, комиссия секретаре тарафыннан имзалана.

«Балтач муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләү турындагы комиссия утырышы беркетмәсеннән өземтә карап тикшерелгән гражданнарның бүләкләү материалларына теркәлә.

Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының берсен бүләкләү турындагы үтенечнамәне караганда, ул комиссия эшеннән вакытлыча читләштерелә һәм бу хакта утырыш беркетмәсендә билге куела.

Комиссия эшен алып бару, документларны саклау һәм куллану комиссия секретаренә йөкләнә.